**РЕШЕНИЕ**
**Совета муниципального образования Малосалтыковского сельского поселения Камско-Устьинского муниципального района Республики Татарстан**

**«16» июнь 2025 ел** **№ 127**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы бишенче чакырылыш депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 105 статьясындагы 1 өлеше белән, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 17 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы бишенче чакырылыш депутатларын сайлауны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы урамы, 9 йорт;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Гагарин урамы, 38 йорт;

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча «Волжские зори» газетасында бастырып чыгарырга һәм Кама Тамагы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге Советы Рәисе А.Г.Җиһаншин